Г. Х. СӘМИГУЛЛИН, К. М. ЗАРИПОВА

ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ ДӨНЬЯ 1





«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ

Г. Х. СӘМИГУЛЛИН, К. М. ЗАРИПОВА

ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ ДӨНЬЯ

Дүртьеллык башлангыч татар мәктәбенең
1 нче сыйныфы өчен дәреслек

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы рөхсәте белән сынап карау өчен басыла

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2005

УДК 373.167.1:502*01
ББК 20.1 я72
С95

Рәссамы *Л. С. Золондинова*

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Сәмигуллин Г. Х.

С95 Әйләнә-тирә дөнья : Дуртьеллык башл. татар мәкт. 1 нче с-фы өчен д-лек / Г. Х. Сәмигуллин, К. М. Зарипова. — Казан : Мәгариф, 2005. — 64 б. : рәс. б-н.
ISBN 5-7761-1523-X

ISBN 5-7761-1523-X

© «Мәгариф» нәшрияты, 2005
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2005



Кар, томаннан көтмәгәндә
Килде чыкты Шүрәлем.
Дәшмимен. Тып-тын торам.
Нишләр икән, дим, күрәлем.
Ул көлә, һәм көлке эзләүдә үтә кич, иртәсе;
Кем кыеп әйтсен аңар сүз, ул — табигать иркәсе!

Г. Тукай

Нәни дусларым!

Таныш булыйк: мин — Шүрәле, әкияттән килдем. Минем белән бергә Су анасы һәм Күбәләк тә килде. Безнең җиребез шундый иркен, болыннарыбыз шундый хуш исле куе үләнле, кырларыбыз тук башаклы, урманнарыбыз шундый бай, елгаларыбыз, күлләребез шундый балыклы! Без сезне шушы байлыкларны күреп танырга, аларны сакларга өйрәтергә тырышырбыз, табигатьнең серле почмакларын ачып күрсәтербез. Әйдәгез, киттек дусларым!

КЕШЕ ҺӘМ УРМАН.

Зур бу урман: читләре күренмидер,
диңгез кеби...

Г. Тукай

Урман нәрсә ул?

— Ни өчен урманда шауларга ярамый?

— Урманымда кунак булыгыз, тик зыян китермәгез.

Татлыдан-татлы нәрсә үсә урманда?

— Сез нинди җиләкләр беләсез? Алар кайда үсә? Сезнең бакчагызда нинди җиләкләр үсә?

Рәсемдәге җиләкләрне тышкы кыяфәте, формасы, тәме буенча чагыштырыгыз.

Бик хозур! Рәт-рәт тора,
гаскәр кеби, чыршы, нарат.

Г. Тукай

Ылыслы урман нинди була?

Нарат белән чыршыны чагыштырыгыз. Аермасын ачыклагыз. Күркә, ботак, ылыс рәсемнәренә туры китереп, урманнан алып кайткан әйберләрегезне тартмачыкларга урнаштырыгыз.



Чыршы Нарат Карагай Ак чыршы Кедр нараты

Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем.

Г. Тукай

Туган ягыбызның яфраклы урманы нинди?

Рәсемдәге агачларның яфракларын чагыштырыгыз.

Көзге урманга экскурсиягә баргач, коелган көзге яфраклар җыеп кайтыгыз. Һәр яфракның кайсы агачтан коелганын ачыклагыз.

Каен Имән Өрәңге Юкә Корыч агач

Ак, кызыл, ал, сап-сары, зәңгәр, яшелдән чәчкәләр;
Һәр тарафка тәмле исләр чәчкәли бу чәчкәләр.

Г. Тукай

Туган ягыбызның үләннәре.

Үлән, куак, агач сүзләрен ачыклагыз.

— Дару үләннәре турында ишеткәнегез бармы?
— Бу үләннәрнең кайсысы шифалы булырга мөмкин?

Өегездә үзегез киптергән дару үләннәре белән чагыштырыгыз.

Үсемлекләргә үсү өчен туфрак, су, һава, яктылык һәм җылылык кирәк.

Ул таныш кырлар, болыннар тартты әүвәл хиссеми;
Тарта торгач куймады, кайтарды ахыр җисмеми.

Г. Тукай

— Ни өчен чәчәкләрне өзәргә ярамый?

Юкә, каеннар төбендә кузгалаклар, гөмбәләр
Берлә бергә үсә аллы-гөлле гөлләр, гонҗәләр.

Г. Тукай

Нәрсә ул гөмбә?

Каен гөмбәсе

Майлы гөмбә

Ак гөмбә

Усак гөмбәсе

Җирән гөмбә

Баллы гөмбә

Әтәч гөмбәсе

— *Гөмбә* һәм *гөмбәлек* сүзләрен сез ничек аңлыйсыз?

Үзегез танып җыя торган гөмбәләрнең рәсемнәрен ясагыз.



Агулы гөмбәләрне танныйсызмы?

Кызыл чебен гөмбәсе

Томсык гөмбә

Чуар чебен гөмбәсе

Күкертсыман сары ялган баллы гөмбә

Сасы чебен гөмбәсе

Саңгырау гөмбә

Кызгылт-сары ялган баллы гөмбә

Агулы гөмбәләрне җыймагыз.
Үзегез белмәгән, танымаган гөмбәләрне дә алмагыз.

БӨҖӘКЛӘР, КОШЛАР ҺӘМ ҖӘНЛЕКЛӘР.

Үпкәлиләр чәчкәләрне төрле төсле күбәләкләр килеп,
киткән булып, тагын да шунда чүгәләп.

Г. Тукай

Нәрсә ул бөҗәк?

Коңгызлар

Кырмыскалар

Үрмәкүчләр

Черки

Төклетура

Чебен

Күбәләк

Бал корты

Рәсемдәге тереклекияләренең аякларын санагыз.

Күбәләкләр чәчәкләрдән тәмле нектар суыралар, бу вакытта чәчәкләрне серкәләндерәләр. Шунсыз чәчәкләрнең җимешләре һәм орлыклары булмый.

Бөҗәкләрне күзәтегез. Охшаш органнарын табып әйтегез.

Һәр бөҗәкнең алтышар аягы бар.
Үрмәкүчнең аягы ... .
Үрмәкүч бөҗәк түгел.

Бервакыт чук-чук итеп сайрый Ходайның кошлары;
Китә җаннарны кисеп, ярып садаи хушлары.

Г. Тукай

Ни өчен кошларны дусларыбыз дип атыйбыз?

— Кайсы кошның сайравын ишеткәнегез бар?

— Кайсы кошның аякларына балдак кидертәләр? Ни өчен?

— Карга кайда кышлый?

— Ни өчен кошларны дусларыбыз дип атыйбыз?

Курыкмагыз, кошлар, күреп сез яныгызда мин барын;
Мин тимәм сезгә, фәкать сайравыгызны тыңларым.

Г. Тукай



Кошмы? Кош түгелме? Очмый торган кош буламы?

Рәсемнәрне карагыз, оча торган кошларны атагыз.
Бу кошлар кайда яши?

Император пингвины

Пеликан

Кошларга кайчан безнең ярдәмебез кирәк?

Туган ягыбызның кошларын таныйсызмы?

— Тагын нинди кошларның рәсемнәре биредә төшерелмәгән?

— Кошларга яшәү өчен ниләр кирәк?

— Кошлар нинди файда китерәләр?

Күп нокталар урынына тиешле сүзләрне куеп укыгыз.

Барлык кошларның да
... бар.
... бар.
... бар.



Билгеле, бу кап-кара урманда һәр ерткыч та бар;
Юк түгел аю, бүре; төлке — җиһан корткыч та бар.

Г. Тукай

Нәрсә ул җәнлекләр?

Арыслан



Кит



Жираф

Дөя



Фил

Ак аю

Болан

И куян, куркак куян, йомшак куян,
Моңланасың нинди хәсрәт, кайгыдан?

Г. Тукай

Туган ягыбызның җәнлекләре.

— Бу җәнлекләргә нинди куркыныч яный?

— Г. Тукайның куян турындагы шигырен укып, нинди нәтиҗә ясарга мөмкин?

Урман һәм аның җәнлекләре — безнең табигый байлыгыбыз. Аларга зарар китермик!

— Кайсы җәнлекләрнең гәүдәләре йон белән капланган?

— Кайсы җәнлекләрнең гәүдә төзелешендә гадәти булмаган нәрсә бар?

— Нинди ерткыч хайваннар беләсез?

— Зоопарк нәрсә ул? Сезнең зоопаркта булганыгыз бармы, анда нинди җәнлекләр күрдегез?

— Рәсемдә нинди җәнлекләр ясалган, алар кайда яши?

Кайда булдыгыз, нәрсә күрдегез?

— Сез урманда сәяхәттә булдыгыз, балалар. Урман һавасының хуш исләрен тойдыгыз, гүзәл чәчәкләрен күреп сокландыгыз, мәһабәт агачларын күреп горурландыгыз, тәмле җиләкләрен татып ләззәтләндегез, гаҗәеп кошларның сайрауларын тыңлап таң калдыгыз, эшчән кырмыскаларны, җитез бал кортларын күзәтеп гаҗәпләндегез.

Минем сорауларыма җавап бирегез:

— Әгәр һәрберегез, урманга килгән саен, берәр читлек алып килеп, шунда берәр кош тотып япса ни булыр?

— Әгәр һәрберегез урман-болыннан чәчәкләр бәйләмен җыеп кайтса?

— Әгәр һәрберегез берәр полиэтилен капчык, судан бушаган шешә, стакан, кәгазь ташлап калдырса?

— Әгәр һәрберегез агач яки куак ботагын сындырса?

— Урманда учак яксагыз һәм аны сүндермичә кайтып китсәгез ни булыр?

Сез — табигатьнең дуслары,
ә табигать — куркыныч астында!

ТАБИГАТЬТӘ СУ.

Җәй көне. Эссе һавада мин суда койнам, йөзәм,
Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзәм.

Г. Тукай



Сусыз яшәп буламы?

— Сез яшәгән төбәк нинди елга яки күл буена урнашкан?

— *Буа, чишмә, кое* сүзләрен ачыклагыз, аларның аермасы нәрсәдә?

— Ни өчен табигый сулыкларны пычратырга ярамый?

— Кирәксезгә күп су сарыф итүчеләргә нәрсә дияр идегез?



Табигатьтә су әйләнеше.

— Өйдә су нигә кирәк?

Бирелгән сүзләрне кертеп текст төзегез:

аш өе (кухня)	тузан
савыт-саба	гөлләр
ванна бүлмәсе	аквариум
кием-салым	чәй
идән	компот

Рәсемгә карап, табигатьтә су әйләнеше турында сөйләгез.

Елга, кое, чишмә суы — төче, тозсыз,
ә диңгез суы — тозлы.

Тик кенә торганда капланды томанга бар һава;
Кар оча, кар себрелә, кар котрына һәм кар ява.

Г. Тукай

Кар һәм боз кайда барлыкка килә?

Күзәтүләр буенча җавап бирегез:

— Киемегезгә яуган кар сез өйгә кергәч нишли?
— Өй түбәсеннән тамып торган тамчылардан һава салкынайгач нәрсә барлыкка килә?
— Юл кырыендагы күлләвек һава суынгач нәрсәгә әверелә?

Ике савытка кар һәм боз тутырып куегыз.
Кар һәм бозны чагыштырыгыз.
Нәтиҗәне нокталар урынына тиешле сүзләрне куеп әйтегез:

кар ак, боз ... ;
кар үтә күренмәле ... ,
боз ... ;
кар көпшәк, боз ... .

Кар һәм боз — туңып каткан су ул.
Боз төссез, үтә күренмәле, уалучан.
Кар ... (әйтеп бетерегез).

Бу сәбәптән аңладым мин, и туган җирем, синең
Җанга ягымлы икәндер ялкының да дулкының!

Г. Тукай

Диңгездә нинди балыклар яши? Ә елгада?

— Нәрсә ул балыклар?

— Рәсемдәге балыкларның кайсылары безнең елгаларда яши? Кайсылары диңгез балыклары?



Тәрәч



Акула

Камбала



Диңгез алабугасы

Палтус

Табышмакка җавап тап.

Башы бар, чәче юк, күзе бар, кашы юк,
Йөрергә аягы юк, суыкка туңмый, эссегә көйми.


Юанбаш балык

Сазан


Карп

Ак амур

Балыклар суда яши. Аларның тәне тәңкәләр белән капланган, йөзгечләре бар.





КҮК ЙӨЗЕНДӘ НӘРСӘ БАР?

Күктә ни булмас дисең, —
очсыз-кырыйсыз күк бит ул!

Г. Тукай

— Балалар, болытлар булмаганда, сез Кояшны көн саен күрәсез. Кояш чыгуын һәм Кояш батуын күзәтә аласыз.

Кояш нинди формада? Аны нәрсә белән чагыштырып булыр иде? Кояшның рәсемен кәгазьдән кисеп буягыз. Нинди төсләр сайларсыз?

Кояш — ялкынланып торган бик зур шар ул. Кояшка туры карамагыз, күзләрегезне бозарсыз, кара күзлектән файдаланыгыз.

Кояш һәм Ай — ике туган агай-эне —
Менә шулай дуслык берлән нәүбәтләшә.

Г. Тукай



Күк җисемнәре.

— Җир нәрсәгә охшаган?
— Җир хәрәкәт итәме әллә тик торамы?
— Глобус нәрсә ул?
— Ни өчен Айда кешеләр яшәми?
— Юрий Гагарин кем ул?
— Җир тирәли нинди корабль очкан?





Кырлар буш кала, яңгырлар ява,
Җирләр дымлана, — бу кайчак була?

Г. Тукай

Ел фасыллары.

Көз.



— Уку елы кайсы айдан башлана?
— Агачлар нигә «чишенәләр»?
— Урамда нинди үзгәрешләр күрәсез?
— Көзге каникул кайсы айда була?

Көз айларын исегездә калдырыгыз.



Һәр җир карланган, сулар бозланган;
Уйный җил-буран, — бу кайчак, туган?

Г. Тукай

Кыш.

— Кышкы каникул кайсы айда була?
— Агачлар ни өчен ак «шәлләрен ябынганнар»?
— Чыршы бәйрәме өчен нинди чыршы файдалану яхшырак (ясалма, чын)?
Боз тавында уйнавыгыз турында сөйләгез.

Кыш айларын исегездә калдырыгыз.

Боз һәм кар эрде, сулар йөгерде;
Егълап елгалар, яшьләр түгелде.
Көннәр озая, төннәр кыскара.
Бу кайсы вакыт?— Я, әйтеп кара.

Г. Тукай

Яз.

— Әниләр бәйрәме кайчан була?

— Язгы каникул кайсы айда була?

— 9 май — Җиңү бәйрәме турында нәрсә беләсез?

— Май аенда олылар бакчада нинди эшләр башкаралар?

Ашлыклар үсте, башаклар пеште;
Кояш пешерә, тиргә төшерә.
Халык ашыга, китә басуга,
Урагын ура, — бу кайчак була?

Г. Тукай

Җәй.

— Җәйге каникул кайсы айларда була?
— Ак икмәкне нәрсәдән пешерәләр? Ә карасын?
— Игенче кем ул?
— Туган көнең кайсы айда?

Ел фасылларын һәм һәр ел фасылына кергән айларны исегездә калдырыгыз.



Йокла, угълым, йом күзең,
Йом, йом күзең, йолдызым;
Кичтән йокың кала да,
Егълап үтә көндезең.

Г. Тукай

Ни өчен төнлә йокларга рәхәтрәк?

— Ни өчен кешеләр көн яктысында эшлиләр, ә төн җиткәч йоклыйлар?

— Ни өчен кеше йокламый булдыра алмый?

— Ни өчен балалар вакытында йокларга тиеш?

— Режим нәрсә ул?

— Йоклар алдыннан нинди гигиена таләпләрен үтәргә кирәк? Ни өчен?

Үзегезнең режимыгызны сәгатьләп язып куегыз.

Җир йоклый тыныч,
Күреп тәмле төш...

Г. Тукай

Төнлә йокламый торган җәнлекләр турында беләсезме?

— Нинди хезмәт кешеләре төнлә дә эшлиләр?
— Нинди җәнлекләр төнлә ауга чыга?

Этнең, песинең, тутый кошның ничек йоклавын күзәтегез. Аннан иптәшләрегезгә сөйләгез.

Янгын сүндерү машинасы 01

Милиция машинасы 02

«Ашыгыч ярдәм» машинасы 03

Бу машиналарда эшләүче кешеләрнең хезмәте турында сөйләгез.

ЖИР ӨСТЕ. ТУФРАК. ТАШЛАР.

Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем.

Г. Тукай

Без нәрсәләрне таптап йөрибез?
Туфрак һәм ташлар нәрсә алар?

— Туфракта нинди тереклек ияләрен күзәтеп була?
— Сез рәсемдәге ташларны очратканыгыз бармы?
— Ташлар төсләре, формалары һәм авырлыклары буенча аерыламы?
— Нинди ташлар төзелештә кулланыла?

Әбиегезнең алкасында да, әниегезнең йөзегендә дә ташлар бар. Аларны асылташлар дип атыйлар.

Гранит

Известьташ

Чакматаш



ҮЗЕБЕЗ ҮСТЕРГӘН ҮСЕМЛЕКЛӘР.

Курыкмый яңгырдан, әгәр булса табигый чын чәчәк,
Чөнки ул яхшы белә: яңгыр аны яхшыртачак.

Г. Тукай

Өйдә, бакчада һәм чәчәклектә нинди чәчәкләр үсә?

— Бүлмә гөлләренең нинди файдасы бар?
— Гөлләрне ничек үстерәләр?
— Сезнең кемгә һәм кайчан чәчәк бүләк иткәнегез бар?

Диффенбахия

Азалия

Лимон

И бәрәңге! Безгә килдең син ерак Америкадан...

Г. Тукай

Яшелчәләр нәрсә алар?

— Нинди яшелчәләр беләсез?

— Яшелчәләрнең кайсы өлешләрен азык итеп файдаланалар? Азык итеп орлыклы җимешләре кулланыла торган яшелчәләрне санагыз.

— Сез яшелчә үстерүдә катнашасызмы?



Бәрәңге

Кәбестә

Помидор

Петрушка

Суган

Борыч

Редис

Ашар алдыннан яшелчәләрне юарга онытмагыз!

...Шунда аңар кып-кызыл, зур алма бирде алмагач...

Г. Тукай

Җиләк-җимешләр турында нәрсә беләсез?

— Кайсы агачта нинди җимешләр үсә?
— Куакларда нинди җиләк-җимешләр үсә?
— Үлән арасында нинди җиләкләр үсә?
— Яшелчә белән җиләк-җимеш арасында нинди аерма бар?

Алма

Чия

Крыжовник

Кара карлыган

Җиләк-җимешләр, яшелчәләр витаминнарга бай.

Саргая таллар, усаклар, алмагачлар һәм каен;
Хәстә төсле, арта сары төс аларда көн саен.

Г. Тукай

Төрле үсемлекләрнең охшашлыгы нәрсәдә?

— Үсемлекләрнең нинди охшаш өлешләре бар?
— Чәчәк төркемнәре нинди үсемлекләрдә була?
— Мәк, борчак, көнбагыш үсемлекләренең кайсы өлешләрен ашыйлар?
— Тагын нинди үсемлекләрнең орлыкларын ашарга ярый?

Күп үсемлекләрнең чәчәкләре чәчәк төркеме булып туплана.

Тамыр, сабак, яфрак, чәчәк, орлыклы җимеш — болар үсемлекләрнең өлешләре.

Кеше үсемлекләрдән ничек файдалана?

Көнбагыш — майлы үсемлек.

Көнбагышны кырда да, бакчада да үстерәләр. Көнбагыш — оешма чәчәклеләр семьялыгыннан бер- яки күпьеллык үлән яки куак үсемлек. Аның 50 ләп төре бар, майлы көнбагышны игеп үстерәләр. Ул — дала үсемлеге, тамыр системасы 2—3 м тирәнлеккә үтеп керә, шуңа күрә корылыкка һәм җилгә бирешми. Бер чәчәк төркемендә меңәр чәчәк була.

Көнбагышның туган җире — Көньяк Америка. Россиядә 17 нче гасырдан үстерелә, 18 нче гасырда көнбагыш орлыгыннан май ала башлыйлар. Хәзер көнбагыш безнең республикада да үстерелә. Орлыгыннан сыек май алалар, хәлвә ясыйлар. Яфракларыннан һәм сабакларыннан терлек азыгы — силос әзерлиләр.

Йөземнәр көнгә каршы ялтырыйлар ләгыль, якуттай...

Г. Тукай

Йөзем кайда үсә?

— Йөземне ничек әзерлиләр?
— Виноград кайда үсә?
— Йөземне кайда кулланалар?

Йөзем җимеше — кеше өчен бик файдалы азык.

Балны кешегә кем бирә?

Умарта кортлары, чәчәкләрдән нектар суырып, бал ясыйлар, аны балавыз кәрәзләргә тутыралар. Умартачылар, кәрәзне умартадан алып, балын суырталар.

— Бал кортлары кайда яши?
— Бал ничек ясала?
— Кешеләргә бал ни өчен кирәк?

Ямьле соң умарталык,
Йөрим мин хәйран калып.
Яратам сары балны,
Корт күче алды сарып.

З. Гомәрова

ДИНОЗАВРЛАР. ИҢ БЕРЕНЧЕ КЕШЕЛӘР.

Һай, гомерләр үтте китте, кайда китте ул заман?
Бу җиһанның дусны дустан аеруы бигрәк яман...

Г. Тукай

Динозаврлар турында сез нәрсә беләсез?

— Кешеләр динозаврлар турында кайдан белгәннәр?

— Ерткыч динозаврлар үсемлекләр белән тукланган динозаврлардан нәрсә белән аерыла дип уйлыйсыз?

— Динозаврлар турында нинди кинофильмнар караганыгыз бар?

Динозаврлар — хәзерге сөйрәлүчеләрнең (ташбакалар, крокодиллар) борынгы бабалары.





Синең өй балчыктан, бөкрәйгән карчыктай...

Г. Тукай

Иң беренче кешеләр ничек яшәгәннәр? Ничек киенгәннәр? Хәзерге кеше ничек киенә?

— Киемнәрне нәрсәләрдән тегәләр?

— Рәсемгә карап, нинди хезмәт кешеләрен атап була?

— Салкын якта ничек киенәләр? Ә җылы якта?

— Киемне кайда тегәләр?

Әкияти киемнәр:
патша, патша кызы, патша улы
(принц, принцесса),
кар кызы киеме рәсемнәрен ясагыз.

Һәр очракның үз киеме бар.



КӨНКҮРЕШТӘГЕ ҖАЙЛАНМАЛАР.

Кеше үзенә нинди җайланмалар уйлап тапкан?

— Электрны өзсәләр, ут сүнсә, кеше нинди чаралар күрә ала?
— Газ плитәсеннән файдаланганда нинди саклану чараларын күрергә кирәк?
— Электр куркыныч була аламы?

Бу урынга нинди кисәтү сүзләрен сайлап язарга мөмкин?

Компьютер белән дуслашып буламы?



— Сезнең мәктәптә компьютер бармы?
— Компьютер нәрсә эшли белә?

Компьютер белем алырга ярдәм итә, сезнең белән уйный ала, музыка һәм видеоөзекләр уйната.





Ул шулай инде, вәләкин бер көе тормый җиһан;
Ул җиһан шатлык белән хәсрәтне бер җиргә җыйган.

Г. Тукай

Нәрсәләрдән сак булырга кирәк?

— Өйдәге әйберләр нинди куркыныч тудыра ала?
— Саксыз эш итү нәрсәгә китерергә мөмкин?
— Светофорның нинди әһәмияте бар?
— Нинди юл билгеләрен беләсез?
— Ни өчен шырпыны нәниләргә бирергә ярамый?
— Даруны ничек кулланырга?
— Өйдә, урамда, елгада нинди куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәргә кирәк?







Тилебәрән орлыгы

Энҗе чәчәк

Карга күзе

Тиле ут

Бүре күзе

Бүре җиләге

Бу үсемлекләр — агулы, аларның җимешләрен һәм башка өлешләрен ашарга ярамый. Агулы үсемлекләрне исегездә калдырырга тырышыгыз. Үзегез белмәгән үсемлекләргә кагылмагыз!

Мәкальне аңлатыгыз.

Иртәгә үкенерлек эшне бүген эшләмә.

БЕЗНЕҢ ИЛЕБЕЗ. БЕЗНЕҢ ӨЕБЕЗ.

Рус җирендә без әсәрле, әзле без,
Тарихында бер дә тапсыз көзге без,
Рус белән тормыш кичердек сайрашып,
Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып.

Г. Тукай

Безнең илебез ничек атала?
Ә республикабыз? Шәһәребез (авылыбыз)?
Анда нинди милләт кешеләре яши?

Россия Федерациясе гербы

Россия Федерациясе флагы

Безнең илебез Россия дип атала. Ул — дөньяда иң зур ил. Россия — безнең ватаныбыз. Аның табигате бай һәм матур.

Мәскәү — илебезнең башкаласы. Безнең илдә зур һәм кечкенә шәһәрләр, авыллар күп. Анда руслар, татарлар, башкортлар, кареллар, комилар, удмуртлар, марилар һәм башка бик күп халык яши.

Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары,
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары,
Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур;
Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур...

Г. Тукай

Республикабыз — Татарстан.
Башкалабыз — Казан.

Татарстан Республикасы гербы


Татарстан Республикасы флагы

— Сез нинди шәһәрдә (авылда) яшисез?

— Сезнең шәһәр (авыл) нинди елга буенда урнашкан?

— Урманыгызда нинди агачлар үсә, нинди җәнлекләр яши?

— Шәһәрегездә (авылыгызда) нинди истәлекле урыннар бар?

— Чит илдән килгән кунакка нинди урыннарны күрсәтер идегез?

— Сездә нинди милләт кешеләре яши?

Ал аякларга башын куйган да йоклый, төш күрә;
Төштә дә тычкан, күсе халкы белән ул эш күрә.

Г. Тукай

Песиегез, этегез һәм кенәри кошыгыз булса, аларга нинди шартлар тудырырга кирәк?

Кичә мин читлек алдым, андагы кошчыкны коткардым,
Күңелсез тоткынымны киң яшел урманга кайтардым.

Г. Тукай

— Шигырьнең эчтәлеге турында сез нәрсә уйлыйсыз? Сезнең шулай эшләгәнегез юкмы?
— Этегез бармы? Ул кайда яши?
— Этегезнең кушаматы ничек?
— Ул сезнең йомышыгызны үти аламы?



ТАВЫШЛАР. ТӨСЛӘР.

Тәрәз каршында
Чыпчыклар хоры.
Сыерчык — солист,
Дәртләнеп җырлый.

З. Минһаҗева

Нинди тавышларга игътибар итәргә кирәк?

— Трамвайга нигә кыңгырау?
— Автобус нинди сигнал бирә?
— Милиционер кайчан сыбызгы куллана?
— Өйдә нинди тавышларны көтеп аласыз һәм яратып тыңлыйсыз? Ә урамда?



Поезддан карап була:
Һәр нәрсә кызык аңа,
Күпме яңалык алда!

Ш. Галиев

Нәрсә ул транспорт?

— Транспорт нәрсә ул?

— Пассажир кем ул?

— Җирдә, күктә, суда, галәмдә нинди транспорт средстволары кирәк?

Юлда нинди билгеләр була? Ни өчен аларны танырга кирәк?

Урамнарны күзәтеп,
Ваемсызны кисәтеп,
Чатта тора светофор,
Сакта тора светофор.

Ш. Галиев



Светофорның кызыл төсе — «Туктагыз», сары төсе — «Игътибар», яшел төсе «Барыгыз» дигән сигналны аңлата.



Җәяүле
юлы

Җәяүлеләр
хәрәкәте
тыела

Велосипедта
йөрү тыела

— Ни өчен юл йөрү кагыйдәләрен белергә һәм үтәргә кирәк?

— Юлда нинди билгеләр була?

— Автобустан төшеп, урам аша чыкканда, ни өчен автобусның — артыннан, ә трамвайның алдыннан чыгарга кирәк?

Ак та, кара да түгел ул,
Ике төстә — ала ул.
Әгәр карамыйча торсаң,
Бәбкәләрне ала ул.

Н. Мәдияров

Төсләрне беләсезме?

— Салават күперендә нинди төсләр бар?

— Светофорның төсләре нәрсә аңлата?

— Әти-әниегез, әби-бабагызның күзләре нинди төстә?

— Татарстан флагында нинди төсләр бар?

— Сабантуй бәйрәмендә нинди төсләр күреп була?

ЭКОЛОГИЯ. СӘЛАМӘТЛЕК.

Ап-ак иде кичә юллар,
Кар явып үткән иде.
Бүген чыксам, корым, төтен
Каралтып киткән инде!

К. Зарипова

Карны нәрсә каралта?

— Сез үзегезнең шәһәрегезне (авылыгызны) нинди итеп күрәсегез килә?

—Ускәч сез шәһәрегезгә (авылыгызга) нинди үзгәрешләр кертер идегез?

«Ускәч кем булырга?» дигән сорауны үзегезгә биреп карагыз. Киләчәктә кем булырга теләвегезне рәсемдә ясап күрсәтегез.

Сок, лимонад, йогурт тәмле,
Савытлары бигрәк ямьле,
Кызганыч та ташларга,
Аяк белән таптарга.

К. Зарипова

Кирәкмәгән әйберләр нәрсә алар?

— Бер генә тапкыр файдалану әйберләре нәрсә алар? Файдалангач, аларны кая куярга?

— Чүп-чар эшкәртү заводында нәрсә эшлиләр?

— Яз көне кар нигә пычрак була?

— Һаваны кемнәр пычрата? Ә елга суын?

— Чисталык — сәламәтлекнең нигезе, дигән мәкальне ничек аңлыйсыз?

— Ни өчен өйдә чисталыкны сакларга кирәк?

Ни булгандыр бер имәнгә —
Имән корый, колачларын
Күккә җәеп ярдәм сорый.

Ш. Галиев

Экология **сүзе нәрсәне аңлата?**

— Һаваны нәрсәләр пычрата?
— Дельфиннар нигә үлә?
— Эколог кем ул?

Экология — әйләнә-тирә дөньябызга сак мөнәсәбәттә булырга өйрәтә торган фән.
22 апрель — «Җир көне» бәйрәме.
Яшел төс — Җирне яклау символы.

Чанада да шуабыз,
Чаңгыда да шуабыз,
Тимераякта очабыз,
Чыжлап тора шома боз.

Н. Мәдияров

Ничек сәламәт яшәргә?

— Сәламәт яшәү рәвеше нәрсә дигән сүз?
— Сәламәтлеккә нәрсә комачаулый?
— Режим нигә кирәк?
— Ни өчен тешләрне чистартырга һәм кулларны юарга кирәк?

— Ни өчен яшелчә һәм җиләк-җимешне күп ашарга кирәк?

Сәламәт булу өчен, көндәлек режимны үтәргә, дөрес тукланырга, үсемлек азыкларны (яшелчәләр, җиләк-җимешләр) җитәрлек кулланырга кирәк.

Сәламәт булу өчен, организмны чыныктырырга, һавада булырга, күбрәк хәрәкәтләнергә кирәк.

ЭЧТӘЛЕК

Кеше һәм урман 6
Бөҗәкләр, кошлар һәм җәнлекләр 14
Табигатьтә су 22
Күк йөзендә нәрсә бар?. 28
Җир өсте. Туфрак. Ташлар 36
Үзебез үстергән үсемлекләр 37
Динозаврлар. Иң беренче кешеләр 44
Көнкүрештәге җайланмалар 46
Безнең илебез. Безнең өебез 50
Тавышлар. Төсләр 55
Экология. Сәламәтлек 59

Учебное издание

Самигуллин Габдулхай Халилович
Зарипова Клара Муллануровна

ОКРУЖАЮЩИЙ МИР

Экспериментальный учебник
для 1 класса четырёхлетней начальной татарской школы

Казань. Издательство «Магариф». 2005

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Сәмигуллин Габделхәй Хәлипович
Зарипова Клара Муллануровна

ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ ДӨНЬЯ

Дүртьеллык башлангыч татар мәктәбенең
1 нче сыйныфы өчен сынап карау дәреслеге

Редакция мөдире *Л. Х. Мөхәммәтҗанова*
Редакторы *Р. З. Закирова*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы *Л. И. Матвеева*
Корректоры *Р. Ә. Фәйзуллина*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Л. Р. Вафина*

Китапта Ф. Г. Әминовның рәсемнәре файдаланылды.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 25.12.2005. Форматы $60 \times 84^1/_8$. Офсет кәгазе. «Букварная» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 7,44. Тиражы 3000 д. Заказ А-1003.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (843) 292-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.